**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

_04.10.2021_ __1052-п_

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшләр башкаруга гомумталралган файдалы казылмалар, җир асты сулары ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын һәм башка проект документларын Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан карау һәм килештерүне оештыру турында

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын һәм җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшләрне башкаруга, файдалы казылмалар төрләре һәм җир асты байлыкларыннан файдалану төрләре буенча башка проект документларын әзерләү, килештерү һәм раслау турында нигезләмә раслау турында» 2010 елның 3 мартындагы 118 номерлы карары, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Каты файдалы казылма ятмаларын эшкәртүгә, тау эшләнмәләрен бетерүгә һәм консервацияләүгә һәм минераллы чималны беренчел эшкәртүгә проект документлары составына һәм аларны рәсмиләштерүгә карата таләпләр раслау турында» 2010 елның 25 июнендәге 218 номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Җир асты сулары ятмаларын эшкәртүгә проект документлары структурасына һәм аларны рәсмиләштерүгә карата таләпләр раслау турында» 2010 елның 27 октябрендәге 463 номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Файдалы казылмаларның төрләре буенча җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм файдалы казылма ятмаларын разведкалауны уздыруга проект документларын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 14 июнендәге 352 номерлы боерыгы, «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмаларның, җир асты суларының ятмаларын эшләү буенча техник проектларны һәм җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләреннән файдалануга бәйле башка проект документларын карау буенча комиссия төзергә;

2. Кушымтада бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмаларның, җир асты суларының ятмаларын эшләү буенча техник проектларны һәм җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләреннән файдалануга бәйле башка проект документларын карау буенча комиссия турында нигезләмә;

Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмаларның, җир асты суларының ятмаларын эшләү буенча техник проектларны һәм җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләреннән файдалануга бәйле башка проект документларын карау буенча комиссия составын.

3. Хокукый тәэмин итү бүлеге әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.И.Гыйбадуллинга йөкләргә.

Министр А.В.Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать ресурслары
министрлыгының 2021 елның 4
октябрендәге 1052-п номерлы
боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмаларның, җир асты суларының ятмаларын эшләү буенча техник проектларны һәм җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләреннән файдалануга бәйле башка проект документларын карау буенча комиссия турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмаларның, җир асты суларының ятмаларын эшләү буенча техник проектларны һәм җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләреннән файдалануга бәйле башка проект документларын карау буенча комиссия (алга таба – Комиссия) үз эшчәнлегендә «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын һәм җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшләрне башкаруга, файдалы казылмалар төрләре һәм җир асты байлыкларыннан файдалану төрләре буенча башка проект документларын әзерләү, килештерү һәм раслау турында нигезләмәне раслау турында» 2010 елның 3 мартындагы 118 номерлы карарына, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Каты файдалы казылма ятмаларын эшкәртүгә, тау эшләнмәләрен бетерүгә һәм консервацияләүгә һәм минераллы чималны беренчел эшкәртүгә проект документлары составына һәм аларны рәсмиләштерүгә карата таләпләр раслау турында» 2010 елның 25 июнендәге 218 номерлы боерыгына, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Җир асты сулары ятмаларын эшкәртүгә проект документлары стуркутрасына һәм аларны рәсмиләштерүгә карата таләпләр раслау турында» 2010 елның 27 октябрендәге 463 номерлы боерыгына, «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына, җир асты байлыклары өлкәсенә кагыла торган Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.2. Комиссия Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына (алга таба – Министрлык) йөкләнгән гомуми таралган файдалы казылма ятмаларын һәм җир асты суларын эшкәртүнең, эчә торган һәм хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм тәүлегенә 500 куб.метрдан артык булмаган геологик разведка эшләре, техник проектлар һәм башка проект документлары проектларын килештерү буенча вәкаләтләрне тәэмин итүче коллегиаль орган булып тора.

1.3. Россия Федерациясенең 2010 елның 3 мартындагы 118 номерлы карары белән расланган  Файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын һәм җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшләрне башкаруга, файдалы казылмалар төрләре һәм җир асты байлыкларыннан файдалану төрләре буенча башка проект документларын әзерләү, килештерү һәм раслау турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә Комиссия компетенциясенә җир асты байлыкларыннан файдалануның түбәндәге төрләренә карата җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре буенча документларны карау керә:

а) гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләүне дә кертеп, геологик өйрәнү, шулай ук файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнү һәм бәяләү;

б) гомумтаралган файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару;

в) уртак лицензия буенча башкарыла торган гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, эзләү һәм чыгару;

г) файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү;

д) файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләүне дә кертеп, геологик өйрәнү, файдалы казылмалар чыгару, уртак лицензия буенча гамәлгә ашырыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү һәм чыгару, –  эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм аларны чыгару күләме тәүлегенә 500 куб.метрдан артмаган җир асты суларына карата.

1.4. Комиссия җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре буенча түбәндәгеләргә карата документларны карый:

а) гомумтаралган файдалы казылмаларга карата – файдалы казылма ятмаларын тәҗрибә-сәнәгать эшкәртү проекты, файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проекты, тау эшләнмәләрен бетерү яки консервацияләүнең техник проекты, гомумтаралган файдалы казылмаларны беренчел эшкәртүнең технологик схемасы;

б) эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган, чыгарылу күләме тәүлегенә 500 куб.метрдан артмаган җир асты суларына карата – су алу проекты.

1.5. Геология-разведка эшләре проектын карау Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 2016 елның 14 июнендәге 352 номерлы боерыгы белән расланган Файдалы казылма төрләре буенча җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм файдалы казылма ятмаларын эзләү өчен проект документларын әзерләү кагыйдәләрен үтәү шарты белән геологик өйрәнү стадиясендә үткәрелә.

1.6. Гомумтаралган файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проектын карау гомумтаралган файдалы казылмаларны чыгара башлаганчыга кадәр гомумтаралган файдалы казылма ятмаларының исәпләнгән запасларын раслаганнан соң һәм аларны балански куйганнан соң үткәрелә.

1.7. Эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм чыгарылу күләме тәүлегенә 500 куб.метрдан артмаган җир асты сулары ятмаларын эшкәртүнең техник проектын карау, җир асты суларын чыгара башлаганчы, җир асты суларының исәпләнгән запасларын раслаганнан соң һәм аларны балански куйганнан соң үткәрелә.

1.8. Карап тикшерүгә тәкъдим ителә торган проект документлары җир асты байлыкларыннан файдалану, табигатьне саклау, җир асты байлыкларыннан рациональ файдалану, эшләрнең куркынычсыз алып барылуына кертелә торган өстәмәләрнең (үзгәрешләрнең) гамәлдәге законнарына туры килүенә объектив бәя бирергә мөмкинлек бирүе һәм лицензия килешүе шартларына каршы килмәү шарты белән, ятманы эшкәртүнең техник проектына өстәмәләр (үзгәрешләр) ятманы эшкәртүнең теләсә кайсы стадиясендә кертелә ала.

1.9. Комиссия әгъзаларына һәм Комиссия эшенә җәлеп ителә торган белгечләргә коммерция серен тәшкил итүче мәгълүматны үз мәнфәгатьләрендә куллану, шулай ук, әгәр ул тапшырылган документларда тиешле гриф билгеләү юлы белән җир асты байлыкларыннан файдаланучы тарафыннан билгеләнсә, аны өченче затларга тапшыру һәм тарату тыела.

## 2. Комиссиянең төп бурычлары

Комиссиянең төп бурычы булып, гомуми таралган файдалы казылма ятмаларын һәм җир асты суларын эшкәртүнең, эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм тәүлегенә 500 куб.метрдан артык булмаган күләмдә чыгарыла торган җир асты сулары ятмаларын эшкәртү буенча геологик разведка эшләре, техник проектлар һәм башка проект документлары проектларын килештерү буенча Министрлыкка йөкләнгән вәкаләтләрне тәэмин итү тора.

## 3. Комиссиянең функцияләре

3.1. Министрлыкка йөкләнгән бурычлар нигезендә Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

- гомумтаралган файдалы казылма ятмаларына геологик разведка эшләрен башкару, аларны эшкәртү өчен проект документларын, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм региональ әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзүгә һәм эксплуатацияләүгә проект документларын, эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб.метрдан артмаган җир асты сулары ятмаларын эшкәртүгә проект документларын һәм, ятмаларны үзләштерүнең техник-икътисадый

күрсәткечләрен, бозылган җирләрне рекультивацияләүне дә кертеп, шулай ук югарыда әйтелгән проект документларына өстәмәләр (үзгәрешләр) кертү буенча тәкъдимнәрне дә кертеп, башка проект документларын карый;

- югарыда күрсәтелгән проект документларын килештерү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында карар чыгара;

- җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары һәм ятмаларны өйрәнеп бетерү буенча (кирәкле күләмдә өстәмә эшләр һәм тикшеренүләр үткәрүне дә кертеп), шулай ук якын-тирә мәйданнарда геологик эзләнү эшләре юнәлеше буенча тәкъдимнәр әзерли;

- тәкъдим ителгән техник проектлар материалларын анализлый һәм ятмаларны эшкәртү һәм рекультивацияләү процессларының сыйфатын күтәрү, оптимальләштерү һәм нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерли;

- Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәт (Ростехнадзор) белән хезмәттәшлек итә;

- гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты суларын чыгаруга бәйле булмаган эшләр башкаруга (җир асты саклагычларын һәм башка җир асты корылмаларын төзү һәм җир асты байлыкларының бөтенлеген бозуга бәйле башка хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча) проект документларын карый.

3.2. Комиссия оешмалар тарафыннан килештерү өчен тапшырыла торган гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты суларын геологик эзләү проектлары һәм ятмаларны эшкәртүнең техник проектлары, бозылган җирләрне рекультивацияләү проектлары, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты суларын чыгаруга бәйле булмаган башка эшләрне уздыруга (җир асты саклагычларын һәм башка җир асты корылмаларын төзү һәм җир асты байлыкларының бөтенлеген бозуга бәйле башка хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга) проект документлары материалларының тулы һәм сыйфатлы булуына контрольлек башкара.

## 4. Комиссиянең составы һәм аның эшен оештыру

4.1. Комиссия составына Министрлык җитәкчеләре, Министрлыкның минерал-чимал һәм су ресурслары һәм җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәләре җитәкчеләре һәм белгечләре керә. Комиссиянең исәбе 13 кеше тәшкил итә һәм Министрлык боерыгы белән раслана.

4.1.1. Комиссия эшенә һәм Комиссия утырышларында, кирәк булганда, консультация хезмәтләре күрсәтү, проект документларының аерым бүлекләрен карау өчен, Министрлыкның профильле бүлекләре белгечләре, Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәт (Ростехнадзор) вәкилләре, Комиссия составына керми торган махсус фәнни-тикшеренү һәм проект оешмалары белгечләре җәлеп ителә.

4.2. Комиссия әгъзалары түләүсез нигездә эшли.

4.3. Комиссия эшен аның рәисе – Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрының җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләрен алып баручы урынбасары җитәкли; Комиссия рәисе урынбасары

булып Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе җитәкчесе тора.

4.4. Комиссия рәисе булмаганда аның функцияләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.

4.5. Комиссия рәисе:

- Комиссия утырышын җитәкли һәм үткәрә;
- Комиссиянең җаваплы секретарен билгели;
- тәкъдим ителгән проект документларын Комиссия тарафыннан карау нәтиҗәләрен килештерә.

4.6. Комиссиянең оператив эшенә түбәндәгеләр җитәкчелек итә:

- Комиссия рәисе урынбасары;
- Комиссиянең җаваплы секретаре.

4.7. Комиссиянең җаваплы секретаре:

- Комиссия эшчәнлеген алып баруны оештыра;
- Комиссиянең эш планнары проектларын эшләүне тәэмин итә;
- Комиссия рәисе белән килештереп, Комиссия утырышын оештыра;
- Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында мәгълүмат белән тәэмин итә;
- Комиссия рәисе күрсәтмәсе буенча Комиссия эшенә бәйле башка функцияләрне башкара.

4.8. Эксперт комиссиясенең аерым әгъзалары карар белән килешмәгән очракта, алар карарны «аерым фикер» тамгасы белән имзалыйлар. Аерым фикер аңа нигезләүне үз эченә алган аерым документ белән рәсмиләштерелә.

4.9. Комиссия утырышы нәтиҗәләре буенча проект документларын карау нәтиҗәләре Комиссиянең җаваплы секретаре тарафыннан проект документларын килештерү мөмкинлеге (мөмкинлегенең булмавы) турында Комиссия карарында (алга таба – Карар) бәян ителә, ул Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм имзаланган көннән башлап 5 эш көне эчендә Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

## 5. Комиссиянең хокуклары

5.1. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

5.1.1. Министрлыкның структур бүлекчәләреннән аның эшчәнлеге өлкәсенә караган мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле мәгълүматны соратырга һәм алырга.

5.1.2. Комиссия утырышына утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләргә кагылышлы җир асты байлыкларыннан файдаланучыларны чакырырга.

5.1.3. Тиешле фәнни-тикшеренү, җитештерү һәм проект оешмаларыннан карала торган мәсьәләләр буенча белгечләрне, тапшырылган документларны һәм материалларны җаваплы башкаручыларны, шулай ук Министрлыкның комиссия составына кермәгән профильле бүлекләре белгечләрен билгеләнгән тәртиптә Комиссия эшенә һәм Комиссия утырышларында катнашуга җәлеп итәргә.

5.1.4. Җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга, дәүләт хакимияте органнарына, оешмаларга үз компетенциясе мәсьәләләре буенча киңәшләр бирергә.

5.1.5. Тау предприятиеләре булган һәм геологик разведка эшләре алып баручы һәм ятмаларны эшкәртүче оешмалардан Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыру турында сорарга:

- минерал-чимал ятмаларын эшкәртү һәм разведкалау яисә эзләнә яки эшкәртелә торган ятмалар буенча еллык планнарны (графикларны);

- чыгарыла торган минерал-чимал кондицияләре ТЭО тикшерү өчен кирәкле геологик һәм башка материалларны;

5.2. Комиссия проект документларын карап тикшерүгә штаттан тыш экспертлар сыйфатында файдалы казылма ятмаларын эзләү, бәяләү һәм эшкәртү өлкәсендә җитәрлек тәҗрибәгә ия булган югары квалификацияле белгечләрне һәм (яки) эксперт оешмасын җәлеп итәргә хокуклы. Җәлеп ителә торган штаттан тыш экспертлар саны карала торган материалларның катлаулылыгы белән җайга салына.

## 6. Комиссия эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итү

6.1. Комиссия утырышлары, әгәр аларда аның әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше булса, хокуклы дип санала.

6.2. Комиссиянең барлык карарлары аның утырышларында ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының «хуплыйм» һәм «каршы» тавышлары тигез булган очракта, рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

6.3. Комиссия тапшырылган материалларны Министрлыкның рәсми мөрәҗәгатьләренә Министрлык боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмалар, җир асты сулары ятмаларын эшкәртү буенча техник проектларны һәм җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләреннән файдалануга бәйле башка проект документларын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган тиешле дәүләт органнарыннан алынган җаваплар Министрлык тарафыннан теркәлгән көннән башлап 20 эш көне эчендә карый.

Уникаль һәм эре файдалы казылма ятмалары буенча проект документларын карау срогы арттырылырга мөмкин, әмма 25 эш көненнән артмаган срокка гына.

5.4. Проект документларын килештерү мөмкинлеге (мөмкин булмавы) турында Комиссия карары мөрәҗәгать итүчегә кулына тапшырыла яисә мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә) Комиссия утырышын уздыру датасыннан соң 5 эш көне эчендә җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать ресурслары
министрлыгының 2021 елның 4
октябрендәге 1052-п номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмаларның, җир асты суларының ятмаларын эшләү буенча техник проектларны һәм җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләреннән файдалануга бәйле башка проект документларын карау буенча комиссия составы

| | |
|---|---|
| Гобәйдуллин Илнур Ирек улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары – Татарстан Республикасында гомумтаралган файдалы казылмаларның, җир асты сулары ятмаларын эшләү буенча техник проектларны һәм җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләреннән файдалануга бәйле башка проект документларын карау буенча комиссия рәисе; |
| Чинарев Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Минерал-чимал һәм су ресурслары идарәсе җитәкчесе – Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшләр башкаруга гомумтаралган файдалы казылмалар, җир асты сулары ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын һәм башка проект документларын карау буенча комиссия рәисе урынбасары; |
| Гафуров Рәсим Вилдан улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының каты файдалы казылмалар геологиясе бүлегенең әйдәп баручы белгече – Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшләр башкаруга гомумтаралган файдалы казылмалар, җир асты сулары ятмаларын эшкәртүнең техник проектларын һәм башка проект документларын карау буенча комиссиянең җаваплы секретаре; |
| Ахманова Татьяна Петровна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының углеводород чималы геологиясе бүлеге җитәкчесе; |
| Васильева Татьяна Леонидовна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының гидрогеология һәм судан |

| | |
|---|---|
| | файдалануны җайга салу бүлеге җитәкчесе; |
| Вахитов Самат Таһир улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе җитәкчесе; |
| Кыямов Альберт Әнәс улы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының мәгълүмат-геология ресурслары һәм геология тирәлеген күзәтү бүлегенең әйдәп баручы белгече; |
| Лукина Людмила Александровна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге җитәкчесе; |
| Мостафина Рәйлә Хафиз кызы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе; |
| Полушин Владислав Леонидович | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының мәгълүмат-геология ресурслар һәм геология тирәлеген күзәтү бүлеге җитәкчесе; |
| Чеснокова Ирина Валерьевна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының җир асты байлыкларыннан файдалануны җайга салу бүлеге җитәкчесе; |
| Шутникова Светлана Анатольевна | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесе. |
| Садриев Илнар Илфат улы | углеводород чималы геологиясе бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече |